СОВЕТ МАКУЛОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Декабристов, д.35 в, с. Печищи, 422592

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
МАКЫЛ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Декабристлар ур., 35 нче йорт, Печищи авылы, 422592

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

РЕШЕНИЕ — КАРАР

07.09.2018 — с. Русское Макулово — 57-237

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

**“Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлеге составына кергән торак пунктларында гражданнар җыены уздыруга әзерлек тәртибе турында” Кагыйдәнамәне раслау турында**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәләрне оештыруның гомуми принциплары турында” 06.10.2003 № 131-ФЗ Федераль канунының 25.1нче маддәсен,”Татарстан Республикасында җирле үзидарәләр турында” Татарстан Республикасы канунының 28.07.2004 ел, № 45-ТРЗ 35нче маддәсен һәм Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының “Макыл авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 24нче маддәсен тормышка ашыру максатыннан,

**Югары Ослан муниципаль районы**
**Макыл авылы җирлеге**
**Советы**
**Карар кылды:**

1. “Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлеге составына кергән торак пунктларында гражданнар җыены уздыруга әзерлек тәртибе турында” Кагыйдәнамәне кушымта буенча расларга.
2. Әлеге карар аны рәсми рәвештә бастырып чыгарган вакыттан соң көченә керә.
3. Аның үтәлешен контрольдә тотуны Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлеге Советы иҗтимагый - мәдәни, тәртип саклау һәм законлылык буенча даими комиссиясенә тапшырырга.

**Совет рәисе,**
**ТР Югары Ослан**
**муниципаль районының**
**Макыл авыл җирлеге Башлыгы** **А.И.Матвеева**

**Татарстан Республикасы**
**Югары Ослан муниципаль районының**
**Макыл авыл җирлеге Советының**
**7нче сентябрь, 2018нче ел №57-237 карарына**
**Кушымта №1**

**Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлеге составына кергән торак пунктларында гражданнар җыены уздыруга әзерлек һәм үткәрү тәртибе турында Кагыйдәнамә**

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлеге составына кергән торак пунктларында гражданнар җыены уздыруга әзерлек һәм үткәрү тәртибе турында әлеге Кагыйдәнамә (алда - Кагыйдәнамә) "Россия Федерациясендә җирле үзидарәләрне оештыруның гомуми принциплары турында" 06.10.2003 № 131-ФЗ Федераль канунының 25.1нче маддәсе,"Татарстан Республикасында җирле үзидарәләр турында" Татарстан Республикасы канунының 28.07.2004 ел, № 45-ТРЗ 35нче маддәсе һәм Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлеге Уставының 24нче маддәсе белән туры китереп эшләнде.

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Гражданнар җыены гомуми, тигез һәм туры ихтыяр белдерү нигезендә үткәрелә.

1.2. Гражданнар җыенында аның территориясендә даими яки күбесенчә яшәүче бу торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукы булган торак пункт халкы катнашырга хаклы.

1.3. Гражданнар җыенында катнашу ирекле һәм ихтыярый.

1.4. Гражданнар җыенда үзләре катнаша, һәм аларның һәрберсе бер тавышка ия.

1.5. Гражданнар җыены әһәмиятле булган мәсьәләләрне халык тарафыннан турыдан-туры хәл итү максатларында үткәрелә.

## Гражданнар җыенының вәкаләтләре

1.6. Гражданнар җыены түбәндәге мәсьәләләр буенча үткәрелә ала:

күрсәтелгән торак пункт аның составына кергән җирлек (муниципаль район) чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча, күрсәтелгән торак пункт территориясе башка җирлек территориясенә күчергә мөмкин булган очракта, торак пунктта;

чикләрне үзгәртү, әлеге җирлекне үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча муниципаль берәмлекнең сайлап куелган органы вәкаләтләре гражданнар җыены белән тормышка ашырылган җирлектә;

сайлау хокукы булган җирлек халкы саны 100дән ким булган җирлекнең сайлап куелган органын оештыру, аның саны һәм вәкаләтләре вакыты турында мәсьәләләр буенча муниципаль берәмлекнең сайлап куелган органы вәкаләтләре гражданнар җыены белән тормышка ашырылган җирлектә;

гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләләре буенча муниципаль берәмлекнең сайлап куелган органы вәкаләтләре гражданнар җыены белән тормышка ашырылган җирлектә;

гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләләре буенча муниципаль район чикләрендә авыллар арасындагы территорияләрдә урнашкан җирлек, шәһәр эчендәге район, федераль әһәмияткә ия булган шәһәрнең шәһәр эчендәге территориясендә урнашкан торак пунктта;

җирле үзидарәне оештыру һәм тормышка ашыру белән бәйле булган мәсьәләләр буенча халыкның инициативасын тәкъдим итү максатыннан авыллар арасындагы территорияләрдә урнашкан җирлектә;

җирлекне бетерү турында мәсьәлә буенча авыл халкы аз яшәгән территориядә урнашкан яки кыен җирләрдә, бу җирлектә яшәүчеләр саны 100дән ким булган җирлектә ;

авыл торак пункты старостасына кандидатура күрсәтү мәсьәләсе буенча, шулай ук авыл торак пункты старостасының вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылу турында мәсьәлә буенча авыл торак пунктында ;

гражданнар җыены Россия Федерациясенең муниципаль хезмәт турында канунда каралган очракта муниципаль хезмәт вазифаларын алыштыруга конкурс уздырган вакытта конкурс комиссиясе составына кандидатуралар күрсәтү максатыннан авыл торак пунктында уздырыла.

**Гражданнар җыенын матди һәм оештыру ягыннан тәэмин итү**

1.7. Җыенны үткәрү Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлеге Башлыгы тарафыннан тәэмин ителә.

1.8. Җыенны әзерләү һәм үткәрү белән бәйле чыгымнар Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлеге бюджеты акчалары хисабына башкарыла.

**2. Гражданнар җыенының чакырылыш тәртибе**

Гражданнар җыенын үткәрү инициативасы.

2.1. Торак пунктында гражданнар җыенын үткәрү инициативасы карый:

- Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлеге Башлыгына;

- гражданнар җыенында катнашырга хокукы булган 10 кешедән ким булмаган сайлау хокукы булган торак пункт халык төркеменә (ягъни, Россия Федерациясенең эшкә яраклы 18 яше тулган, шушы территориядә яшәүче, сайлау хокукы булган гражданнары, Россия Федерациясе халыкара килешүләре һәм федераль кануннар белән туры китереп җирле үзидарәне тормышка ашырганда хокуклары булган һәм җирлек торак пункты территориясендә даими яки күпчелек яшәүче чит ил гражданнары).

2.2. Торак пункт халкы инициативасы култамгалар **(кушымта №1)** яки инициатив төркемнең гражданнар җыенын үткәрү инициативасын күрсәтү турында карар кабул ителгән җыелыш беркетмәсе хәлендә рәсмиләштерелергә тиеш, беркетмәдә гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләләр, тәкъдим ителгән гражданнар җыенын үткәрү вакыты, гражданнар җыенын чакырту турында инициативаны хуплаучы һәр гражданинның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, туган көне, паспорт сериясе һәм номеры, яки аны алыштыручы документ, яшәү урыны адресы; аның имзасы һәм имзасын кую вакыты күрсәтелә.

2.3. Җыенны үткәрү инициативасын хуплау өчен җыерга кирәк булган имзалар саны шушы территориядә яшәүче, сайлау хокукы булган гражданнар санының 5 процентын тәшкил итә, ләкин 25 имзадан да ким булырга тиеш түгел.

2.4. Имзаланган култамгалар раслау вакыты, гражданнар җыенын чакырту турында инициативаны хуплаучы һәр гражданинның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, туган көне, паспорт сериясе һәм номеры, яки аны алыштыручы документ, яшәү урыны адресы күрсәтелеп имзалар җыюны тормышка ашыручы шәхес тарафыннан раслана һәм муниципаль берәмлекнең Башлыгына җибәрелә.

## Гражданнар җыенын үткәрү турында карар кабул итү тәртибе

2.5. Инициатив төркем тарафыннан җыелган гражданнар җыены Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлеге Советы карары белән **(кушымта №2)**, ә авыл җирлеге инициативасы буенча - авыл җирлеге Башлыгы карары буенча **(кушымта №3)** барлык кирәкле документлар кергән көннән соң 30 көн эчендә билгеләнә.

2.6. Авыл җирлеге Башлыгы яки авыл җирлеге Советы аның максатка ярашлы булмаган мотивлары буенча гражданнар җыенын үткәрүгә баш тартырга хаклы түгел.

2.7. Гражданнар җыенына кертелгән мәсьәлә Россия Федерациясе канунына һәм Татарстан Республикасы канунына каршы килергә тиеш түгел. Гражданнар

җыенына кертелгән мәсьәлә шундый итеп формалаштырылган булырга тиеш ки, аны күп тапкырлар аңлату мөмкинлеге кирәк түгел, бәлки аңа бертөрле генә җавап бирергә мөмкин булырга тиеш.

2.8. Гражданнар җыенын билгеләү турында, аны күчерү турында карарны рәсми рәвештә бастырып чыгару (халыкка җиткерү) тәртибе Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлеге Уставы белән билгеләнә һәм муниципаль хокук актларын бастырып чыгару (халыкка җиткерү) өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлеге Уставы белән каралган тәртиптә бастырып чыгарыла (халыкка җиткерелә).

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлеге Башлыгы карарында яки Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлеге Советының гражданнар җыенын үткәрү турында карарында күрсәтелә: гражданнар җыенына кертелгән мәсьәлә; гражданнар җыенын үткәрү вакыты һәм урыны турында мәгълүмат; җыенны оештыручы турында мәгълүмат.

2.9. Гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү өчен җаваплы булган Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлеге Башкарма комитеты Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлеге Башлыгы карары яки Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлеге Советының гражданнар җыенын үткәрү турында карары нигезендә сайлау хокукы булган торак пункт халкының исемлекләрен төзи, гражданнар җыенына мәгълүмат материалларын әзерли, массакүләм мәгълүмат чараларында яки башка юл белән гражданнар җыены турында халыкка хәбәр итә **(кушымта №4)**.

Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлеге Башкарма комитеты гражданнар җыенын үткәрү өчен бина бирергә тиеш.

2.9.1. Торак пункт халкына гражданнар җыенын үткәрү вакыты һәм урыны турында алдан ук хәбәр ителә. Гражданнар җыенын билгеләү турында карар, гражданнар җыенын үткәрү вакыты һәм урыны гражданнар җыенын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча һичшиксез бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

2.9.2. Гражданнар җыенының һәр катнашучысы гражданнар җыенын үткәрү датасына кадәр 5 көннән дә соңга калмыйча әлеге Кагыйдәнамәнең 2.9. пунктында күрсәтелгән гражданнар җыенына кертелгән материаллар белән Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлеге Башкарма комитетында танышырга хокуклы, шулай ук аларның күчермәләрен алырга хаклы.

2.10. Гражданнар җыены турында Кагыйдәнамәгә туры китереп гражданнар җыенын үткәрү датасы сонгы срокка күчерелергә мөмкин. Гражданнар җыенын

үткәрү датасын күчерү турында карар җыенны үткәрү датасы билгеләнгән вакыттан 10 көнгә соңга калмыйча кабул ителергә тиеш.

### 3. Гражданнар җыенын үткәрү тәртибе

3.1. Җыенга килгән гражданнар Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлеге Башлыгы тарафыннан җыенда катнашучы, торак пункт халкы исемлегенә кертелгән һәм сайлау хокукы булган затларны теркәү өчен билгеләнгән вәкаләтле зат тарафыннан теркәү узалар. Исемлектә гражданинның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, туган елы, тору урыны адресы, паспорт сериясе һәм номеры күрсәтелә.

3.2. Җыенга тавыш бирү хокукы булмаган, җыенда катнашу теләген белдергән башка гражданнар, җыенда тикшерелгән мәсьәләләр аларның эшчәнлеге белән бәйле булган предприятие, учреждение, оешма җитәкчеләре, матбугат һәм башка массакүләм мәгълумат чаралары вәкилләре кертелә.

3.3. Сайлау хокукы булган торак пункт халкы исемлегендә төгәлсезлек ачыкланган очракта, торак пунктта яшәүче Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлеге Башлыгы тарафыннан теркәлә һәм халык җыенында катнашуга кертелә ала.

3.4. Язмадагы төгәлсезлекне (яки аларның булмауын) раслау булып гражданинның шәхесен раслаучы документ тора (Россия Федерациясе гражданины паспорты, хәрби билеты, чит ил гражданины паспорты, Россия Федерациясендә яшәүгә рөхсәт, Россия Федерациясендә вакытлыча яшәүгә рөхсәт һ.б.)

3.5. Гражданнар җыены, анда сайлау хокукы булган торак пункт халкының яртысыннан артыгы катнашса, хокуклы була. Кворум булмаган очракта гражданнар җыенын үткәрүнең яңа датасы Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлеге Башлыгы тарафыннан билгеләнә. Бу очракта гражданнар җыены гражданнар җыенын үткәрү билгеләнгән көннән ун көннән дә иртәрәк була алмый.

3.6. Гражданнар җыены карары ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә.

3.7. Ачык тавыш бирү гражданнарның кул күтәрү юлы белән тормышка ашырыла.

3.8. Гражданнар җыенында Макыл авыл җирлеге Башлыгы рәислек итүче була.

3.9. Гражданнар җыены сәркатипне һәм санау комиссиясен сайлый. Санау комиссиясе әгъзалары саны ике кешедән ким булырга тиеш түгел. Гражданнар җыены көн тәртибенә өстәмә сораулар рәислек итүче, гражданнар җыенында катнашу хокукы булган гражданнар тарафыннан кертелә ала. Гражданнар җыенын җыю инициаторлары керткән сораулар көн тәртибенә мәҗбүри кертелә. Күрсәтелгән сораулар беренче чиратта карала. Гражданнар җыены көн тәртибенә өстәмә

сораулар кертү турында карар, аның өчен җыенда катнашучы гражданнарның яртысыннан артыгы тавыш бирсә, кабул ителгән булып санала.

3.10. Гражданнар җыенын җыенда рәислек итүче ача. Гражданнар җыенында рәислек итүче гражданнар җыенын үткәрүне оештыра, тәртип саклый, санау комиссиясе эшен килештерә, тикшерелә торган мәсьәләләр буенча чыгыш ясау өчен сүз бирә, билгеләнгән тавыш бирү тәртибен тәэмин итә.

3.11. Гражданнар җыенында сәркатип гражданнар җыенын үткәрү вакыты һәм урыны, торак пунктта яшәүчеләрнең гомуми саны, сайлау хокукы булган гражданнар саны, катнашучылар саны, көн тәртибе, чыгышларның кыскача эчтәлеге, тикшерелгән мәсьәләләр буенча тавыш бирүчеләрнең санын күрсәтеп беркетмә алып бара **(кушымта №5)**.

3.12. Беркетмәгә гражданнар җыенында рәислек итүче һәм сәркатип кул куя. Беркетмәгә җыенда теркәлгән катнашучылар исемлеге теркәлә.

## 4. Гражданнар җыены карарлары

4.1. Гражданнар җыены карары, анда сайлау хокукы булган гражданнар җыенында катнашучыларның яртысыннан артыгы тавыш бирсә, хокуклы була.

4.2. Гражданнар җыенында кабул ителгән карарлар муниципаль хокук актлары булып тора, Макыл авыл җирлеге Башлыгы тарафыннан имзалана һәм Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокук актлары регистрына кертелергә тиеш **(кушымта №6,7)**.

4.3. Җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарәнең дәүләт хезмәтендәге шәхесләре җирлек Уставы белән билгеләнгән алар арасында вәкаләтләрне чикләү белән туры китереп, гражданнар җыенында кабул ителгән карарларның үтәлүен тәэмин итәләр.

4.4. Җыенда кабул ителгән карар җыенда башка карар кабул итү юлы белән бетерелә яки үзгәртелә ала, яки суд тәртибендә нәтиҗәсез дип табыла.

4.5. Гражданнар җыенында кабул ителгән карарлар рәсми рәвештә бастырылып чыгарыла (халыкка җиткерелә) һәм муниципаль норматив хокук актлары өчен таләпләр белән килештереп рәсмиләштерелә.

4.6. Торак пункт халкының ихтыяр белдерүләре белән кабул ителгән карарларны тормышка ашыру өчен өстәмә муниципаль хокук актлары кабул итү (чыгару) кирәк булса, аларның компетенциясенә күрсәтелгән актны кабул итү (чыгару) кергән җирле үзидарә органы һәм җирле үзидарәнең дәүләт хезмәтендәге шәхесе гражданнар җыенында кабул ителгән карар көченә кергән көннән соң 15 көн эчендә тиешле муниципаль хокук актын әзерләү һәм (яки) кабул итү вакытын билгеләргә тиеш. Күрсәтелгән вакыт өч айдан артып китә алмый.

**Гражданнар җыены карарларын үтәү**

4.7. Гражданнар җыенында кабул ителгән карарлар торак пункт территориясендә һичшиксез үтәлергә тиеш һәм нинди дә булса дәүләт власте органнары, аларның дәүләт хезмәтендәге шәхесләре яки җирле үзидарә органнары тарафыннан раслауга мохтаҗ түгел.

4.8. Гражданнар җыенында кабул ителгән карарларны үтәмәү канунга туры китереп җаваплылыкка тартыла.

Югары Ослан муниципаль районының
Макыл авыл җирлеге составына кергән
торак пунктларында гражданнар җыены уздыруга
әзерлек һәм үткәрү тәртибе турында Кагыйдәнамәгә
**Кушымта №1**

# култамга

Без, түбәндә язылучылар, Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлегенә керүче ________ авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләләре буенча гражданнар җыенын үткәрү инициативасын хуплыйбыз

| № | Фамилия, исем, әтисе исеме | Туган көне | Яшәү урыны адресы | Паспортның яки аны алыштырган документның сериясе, номеры | Имза датасы | Имза |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |

Култамганы раслыйм ________________________________________________
(имзалар җыючы затның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме,
________________________________________________________________

туган көне, яшәү урыны, паспортның яки аны алыштырган документның сериясе, номеры )

____________________ (имза һәм дата)

Югары Ослан муниципаль районының
Макыл авыл җирлеге составына кергән
торак пунктларында гражданнар җыены уздыруга
әзерлек һәм үткәрү тәртибе турында Кагыйдәнамәгә
**Кушымта №2**

СОВЕТ МАКУЛОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Декабристов, д.35 а, с. Печищи,
422592

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
МАКЫЛ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Декабристлар ур., 35 нче йорт, Печищи авылы,
422592

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

РЕШЕНИЕ КАРАР

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

_______________ с. Русское Макулово _______________

**Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлегенең _______ авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләләре буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарәләрне оештыруның гомуми принциплары турында" 06.10.2003 № 131-ФЗ Федераль канунының 25.1нче маддәсенә,"Татарстан Республикасында җирле үзидарәләр турында" Татарстан Республикасы канунының 28.07.2004 ел, № 45-ТРЗ 35нче маддәсенә һәм Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлеге Уставының 24нче маддәсенә туры китереп,

**Югары Ослан муниципаль районы**
**Макыл авылы җирлеге**
**Советы**
**Карар кылды:**

1. 2018нче елның _______ Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлегенең ___________авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү мәсьәләләре буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләне расларга:

"Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлегенең _______ авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 2019нчы елда ______сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә, алынган

акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча урын өчен әһәмиятле булган мәсьәләләрне чишүгә юнәлтүгә сез ризамы:

“Әйе ” “Юк”

3. Гражданнар җыенын ___________адресы буенча __________бинасында ______сәгатьтә үткәрергә.

4. Гражданнар җыенын оештыручы итеп Макыл авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны “Идел яңалыклары” район гәҗитендә, Югары Ослан муниципаль районы рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокук мәгълуматы рәсми порталында, шулай ук мәгълумат стендларында кабул иткән көннән соң 7 көн эчендә урнаштырырга.

6. Әлеге карар аны бастырып чыгарганнан соң үз көченә керә.

**Совет рәисе,**
**ТР Югары Ослан**
**муниципаль районының**
**Макыл авыл җирлеге Башлыгы** **А.И.Матвеева**

Югары Ослан муниципаль районының
Макыл авыл җирлеге составына кергән
торак пунктларында гражданнар җыены уздыруга
әзерлек һәм үткәрү тәртибе турында Кагыйдәнамәгә
**Кушымта №3**

ГЛАВА МАКУЛОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Декабристов, д.35 а, с. Печищи,
422592

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
МАКЫЛ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Декабристлар ур., 35 нче йорт, Печишче авылы,
422592

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

_______________ с. Русское Макулово _______________

**“Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлегенең _______ авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләләре буенча гражданнар җыенын билгеләү турында”**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәләрне оештыруның гомуми принциплары турында” 06.10.2003 № 131-ФЗ Федераль канунының 25.1нче маддәсенә,”Татарстан Республикасында җирле үзидарәләр турында” Татарстан Республикасы канунының 28.07.2004 ел, № 45-ТРЗ 35нче маддәсенә һәм Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлеге Уставының 24нче маддәсенә туры китереп,

**Карар бирәм :**

1. 2018нче елның _______ Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлегенең _______авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү мәсьәләләре буенча гражданнар җыенын билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләне расларга:

“Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлегенең _______ авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 2019нчы елда ______сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә, алынган

акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча урын өчен әһәмиятле булган мәсьәләләрне чишүгә юнәлтүгә сез ризамы:

"Әйе " "Юк"

3. Гражданнар җыенын __________адресы буенча _________бинасында ______сәгатьтә үткәрергә.

4. Гражданнар җыенын оештыручы итеп Макыл авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны "Идел яңалыклары" район гәҗитендә, Югары Ослан муниципаль районы рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокук мәгълуматы рәсми порталында, шулай ук мәгълумат стендларында кабул иткән көннән соң 7 көн эчендә урнаштырырга.

6. Әлеге карар аны бастырып чыгарганнан соң үз көченә керә.

**Совет рәисе,**
**ТР Югары Ослан**
**муниципаль районының**
**Макыл авыл җирлеге Башлыгы** **А.И.Матвеева**

Югары Ослан муниципаль районының
Макыл авыл җирлеге составына кергән
торак пунктларында гражданнар җыены уздыруга
әзерлек һәм үткәрү тәртибе турында Кагыйдәнамәгә
**Кушымта №4**

# Исемлек

Сайлау хокукы булган____________________________________________________

_________________________________ _______________________________яшәүчеләр
(торак пункт исеме) (җирлек исеме)
«___» __________________ 20___ ел

| № | Фамилия, исем, әтисенең исеме | Туган елы ( 18 яшькә кадәр - туган көне, ае) | Яшәү урыны адресы | Паспортның сериясе, номеры | Имза |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |

Гражданнар җыенында рәислек итүче __________ ______________________
(имза) (имзаның расшифровкасы)
Гражданнар җыены сәркатибе __________ ________________________
(имза) (имзаның расшифровкасы)

Югары Ослан муниципаль районының
Макыл авыл җирлеге составына кергән
торак пунктларында гражданнар җыены уздыруга
әзерлек һәм үткәрү тәртибе турында Кагыйдәнамәгә
**Кушымта №5**

# Гражданнар җыены беркетмәсе

________________________________________________________

«___» ____________ 20__ ел № _____

____________________________________
(торак пункт исеме)

Катнашты _________________________________________________________ кеше.
(торак пунктта яшәүчеләрнең гомуми саны, сайлау хокукы булганнарның гомуми саны, катнашучылар саны)

Гражданнар җыенында рәислек итүче __________________________________________________
(фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)
Гражданнар җыенының сәркатибе____________________________________________
(фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)

## Көн тәртибе:

1.

2.

**Беренче мәсьәлә буенча тыңладык:**

_____________________________________________________
(фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)
(чыгышның кыскача язмасы яки доклад тексты (теркәлә)

**Чыгыш ясадылар:** 1. _____________________________________________________
(фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)
(чыгышның кыскача язмасы яки доклад тексты (теркәлә)
Һ.б. (чыгыш ясаучы гражданнар саны буенча)…

**Карар кылдык :** (карарның эчтәлеге)

Тавыш бирү нәтиҗәләре : «Әйе» - ____ кеше
«Юк» - ____ кеше
«Тыелып калды» - ___ кеше.
Карар__________________________
(кабул ителде (кабул ителмәде)

**Икенче мәсьәлә буенча тыңладык:**

_____________________________________________________
(фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)
(чыгышның кыскача язмасы яки доклад тексты (теркәлә)

**Чыгыш ясадылар:** 1. ____________________________________________

(фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)

(чыгышның кыскача язмасы яки доклад тексты (теркәлә)

Һ.б. (чыгыш ясаучы гражданнар саны буенча)…

**Карар кылдык :** (карарның эчтәлеге)

Тавыш бирү нәтиҗәләре : «Әйе» - ____ кеше

«Юк» - ____ кеше

«Тыелып калды» - ___ кеше.

Карар______________________

(кабул ителде (кабул ителмәде)

Гражданнар җыенында рәислек итүче ____________________________________________

(фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)

Гражданнар җыенының сәркатибе______________________________________

(фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)

Югары Ослан муниципаль районының
Макыл авыл җирлеге составына кергән
торак пунктларында гражданнар җыены уздыруга
әзерлек һәм үткәрү тәртибе турында Кагыйдәнамәгә
**Кушымта №6**

# Карар
# Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлегенең _______ авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарәләрне оештыруның гомуми принциплары турында" 06.10.2003 № 131-ФЗ Федераль канунының 25.1нче маддәсенә,"Татарстан Республикасында җирле үзидарәләр турында" Татарстан Республикасы канунының 28.07.2004 ел, № 45-ТРЗ 35нче маддәсенә туры китереп, 20** елда _______ Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлегенең _______ авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү мәсьәләләре буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча"Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлегенең _______ авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 20** елда ______сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә, алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча:1)...;2)... урын өчен әһәмиятле булган мәсьәләләрне чишүгә юнәлтүгә сез ризамы"дигән мәсьәлә буенча беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә буенча:

Сайлау хокукы булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы____кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашучы гражданнар җыенында катнашучылар саны ____кеше.

Гражданнар җыенында катнашучыларның сайлау нәтиҗәләре буенча тавышлар түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен ___ гражданнар җыенында катнашучы тавыш бирде;
«Юк» позициясе өчен ___ гражданнар җыенында катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәргә нигезләнеп гражданнар җыены карар кылды:

1. Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлегенең _______ авылында гражданнар җыены булган, гражданнар җыены нәтиҗәләре – дөрес дип танырга.
2. "Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлегенең _______ авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 20** елда ______сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә, алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча:1)...;2)... урын өчен әһәмиятле булган мәсьәләләрне чишүгә юнәлтүгә сез ризамы"дигән мәсьәлә буенча карарны кабул ителгән дип танырга.
3. Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлегенең _______ авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү мәсьәләләре буенча гражданнар җыены нәтиҗәләрен Макыл авыл җирлеге мәгълумат стендларында халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокук актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлеге Башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче __________ ________________________

(имза) (имзаның расшифровкасы)

Югары Ослан муниципаль районының
Макыл авыл җирлеге составына кергән
торак пунктларында гражданнар җыены уздыруга
әзерлек һәм үткәрү тәртибе турында Кагыйдәнамәгә
**Кушымта №7**

# Гражданнар җыены карары

___________________________________________________________

(Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлегенең _______ авылында
«___» ____________ 20__ ел №_____

"Россия Федерациясендә җирле үзидарәләрне оештыруның гомуми принциплары турында" 06.10.2003 № 131-ФЗ Федераль кануныың 25.1нче маддәсенә,"Татарстан Республикасында җирле үзидарәләр турында" Татарстан Республикасы кануныың 28.07.2004 ел, № 45-ТРЗ 35нче маддәсенә туры китереп

_____________________________________________________ гражданнар җыены **_карар кылды :**
(торак пункт исеме)

1.
2.
3.

Гражданнар җыенында рәислек итүче _________ ______________________
(имза) (имзаның расшифровкасы)